**Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь, 2025 ел № 999-п

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елның беренче кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Торак коды, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителергә тиешле мөлкәт хакын «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге»нең 2025 елның 05 маендагы 292 номерлы хаты белән таянып, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 3 478 975,50 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 4 427 787,00 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 5 692 869,00 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 7 590 492,00 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 9 488 115,00 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 11 385 738,00 сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 13 283 361,00 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 45 584,00

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 29 008,04 сум

1.2.3. Өч кеше һәм аннан да күбрәк гаилә өчен - 24 864,03 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күләмнәрне наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И. Р. Дәүләтханов